Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш Кичүе авыл җирлегенең Йолдыз поселогы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# КАРАР

2019 елның 22 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2019 елның 11 ноябрендәге 18 номерлы Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Чуаш Кичүе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуваш Кичүе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 10 октябрендәге 17 номерлы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш Кичүе авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе» карары, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш Кичүе авыл җирлегенең Йолдыз поселогы торак пунктында гражданнар җыенының 2019 елның 23 ноябрендәге 1 номерлы беркетмәсе нигезендә гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

**1.** Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш Кичүе авыл җирлеге составына керүче Йолдыз поселогы торак пунктындагы гражданнар җыенын үткәрелгән, ә җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

**2.** «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш Кичүе авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләрдән, көндезге формада белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк өлкән яшьтәге гражданнардан тыш, 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:
алардан:

- Яктырту җиһазларын ремонтлау буенча электромонтаж эшләре, электр товарлары сатып алу һәм урам утлары кулланган энергия өчен түләүгә -160 сум.

- Җирлек эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту (грунт, ком, вак таш сибү, тигезләү, юллар салу өчен төзелеш материаллары сатып алу, кышкы чорда юлларны карап тоту, юл кырыйларын грейдлаштыру, юл кырыйларын чабу, «Беларусь 82 " тракторын тоту) - 200 сум.

-Башняларны лицензияләү, урамдагы су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, территорияне коймалау һәм суэтем башняларын буяу, лаборатор-инструменталь тикшеренүләр өчен түләү, суэтем башняларын электр энергиясе өчен түләүгә-140 сум.

- Контейнерлар сатып алу, белгеч эшенә түләүгә-50 сум

- Коймаларны ремонтлау һәм зиратны төзекләндерүгә-50 сум мәсьәләләре буенча карар кабул ителгән дип санарга.

**3.** Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш Кичүе авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күпбалалы гаиләләр, 80 яшьтән өлкәнрәк затлар һәм көндезге формада белем алучы студентлардан кала, 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:
алардан:

- Яктырту җиһазларын ремонтлау буенча электромонтаж эшләре, электр товарлары сатып алу һәм урам утлары кулланган энергия өчен түләүгә -160 сум.

- Җирлек эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту (грунт, ком, вак таш сибү, тигезләү, юллар салу өчен төзелеш материаллары сатып алу, кышкы чорда юлларны карап тоту, юл кырыйларын грейдлаштыру, юл кырыйларын чабу, «Беларусь 82 " тракторын тоту) - 200 сум.

-Башняларны лицензияләү, урамдагы су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, территорияне коймалау һәм суэтем башняларын буяу, лаборатор-инструменталь тикшеренүләр өчен түләү, суэтем башняларын электр энергиясе өчен түләүгә-140 сум.

- Контейнерлар сатып алу, белгеч эшенә түләүгә-50 сум

- Коймаларны ремонтлау һәм зиратны төзекләндерүгә-50 сум

4.Халык җыены нәтиҗәләрен Чуаш Кичүе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми http://pravo.tatarstan порталында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әлки муниципаль районы
Чуаш Кичүе авыл җирлеге башлыгы: И.А.Мамбетова